СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №43 (7216) | 13 апрель, 1991 ел ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## Өмә штабында

10 апрельдә КПСС райкомы секретаре А. А Коростелев җитәкчелегендә В. И. Ленинның тууына 121 ел тулу уңаеннан үтәчәк 20 апрельдәге өмәне оештыру штабының беренче утырышы үтте. Шәһәр предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре партия оешмалары секретарьлары катнашында узган бу утырышта штабның өмәгә хәзерлек һәм аны үткәрү буенча эш планы тикшерелде, партия оешмаларының, җирле газета һәм радионың өмәгә хәзерлек этабындагы бурычлары тикшерелде, шәһәрне төзекләндерү, санитар чистарту, үрнәк тәртип һәм чисталык булдыру юнәлешендә башкарасы эшләр ачыкланды.

# ЯЗ ИШЕК КАГА: механизатор, син аңа әзерме?

## Уңай бәя алдылар



**Техниканың язгы кыр эшләренә хәзерлеген тикшерү эшен тәҗрибәле механизаторларга, бигрәк тә күрше хуҗалык механизаторларына тапшыру бик яхшы уйлап эшләнгән. Чөнки биредә бернинди кимчелекләр дә күз уңыннан төшмәячәк, тикшерүчеләр техниканың һәр детален, һәр өлешен күз уңыннан җентекләп тикшерәләр. Ә үзара тикшерү нәтиҗәләре нәрсә күрсәтә соң?**

x x x

**«Үрнәк» колхозы.**

9—10 апрельдә «Үрнәк» һәм «Игенче» колхозларында булып үткән үзара тикшерү барышында һәр ике хуҗалык механизаторларының хезмәте уңай бәя алды. Икесендә дә авыл хезмәтчелләре язгы чәчү чорына барлык төр техниканы әйбәтләп хәзерләгәннәр. Хәзер алар агрегатларга беркетелеп, көйләп тә куелган инде, басуга чыгарга теләсә кайсы көннән әзер. Хуҗалыкларның алдынгы механизаторларыннан, белгечләреннән төзелгән комиссияләр әнә шундый фикергә килделәр.

**И. ШӘЙХИЕВ,**
«Үрнәк» колхозы партия оешмасы секретаре.

**«Большевик» колхозы.** Ике бригада да тракторлар паркы 100 проценты белән кыр эшләренә көйләнгән. Механизаторлар намус белән эшләделәр. Билгеле, күршеләре күзеннән бер генә кимчелек тә узмады, җитешселекләрне шунда ук әйтеп салдылар. Әмма нигездә техника кырга чыгарга әзер.

x x x

**«Родина» колхозы.** Быел механиаторлар язгы чәчүгә һичкайчан булмаганча тырышып хәзерләнделәр. Бу өлкәдә бик күп эшләр башкарылды. Тракторлар белән эш мәшәкатьле булды, проблемалар аз булмады. Әмма бүген барысы да эшләнгән, хәл ителгән. Кадрлар мәсьәләсе дә борчу тудырмый. Кешеләрнең кәефләре әйбәт. Димәк, чәчү тиешле дәрәҗәдә үткәреләчәк.

x x x

**Ульянов исемендәге колхоз.** Тикшерү көнендә тракторлар паркының язгы кыр эшләренә әзерлеге 94 процент иде, запас частьләр белән хәл мөш келрәк. Язгы чәчүгә хәзерлек мәсьәләсендә башка кимчелекләр алай күзгә зур ташланмады.

x x x

**Хафизов исемендәге колхоз.** Барлык техника да әзерлек сызыгында. Тик Сергиевскига ремонтка җибәрелгән бер тракторны гына көтәсе бар. Озакламыйча ул да кайтып җитәчәк. Хуҗалыкта шушы көннәрдә җыен уздырырга уйлыйлар. Анда язгы чәчүгә хәзерлек мәсьәләсе турында тагын бер кат җитди сөйләшү булачак.

x x x

**«Төрнәс» совхозы.** Ике трактордан кала башка техника кыр эшләренә әзер. Якын көннәрдә бу эшләр дә ахырынача башкарылыр. Хуҗалыкта культивацияне ике сменада, башка эшләрне бер сменада алып бару күздә тотыла. Механизаторлар беркетелгән. Шәһәрнең техника белән булышуына өмет баглыйлар биредә. «Безгә 4 трактор вәгъдә иткәннәр иде», диләр.

**«Рассвет» совхозы.** Биредә трактор паркы кыр эшләренә яхшы хәзерләнгән. Монда тәҗрибәле инженер-техник персоналның өлеше зур. Билгеле булганча, тракторлар ел әйләнәсенә ялга туктатылмыйлар. Алар кырда гына түгел, фермаларда да җитешми. Биредә иң мөһиме техниканы вакытында ремонтлау. Тракторчылар Вазыйх Вәлитов (ДТ-75), Володя Кузьмин (ДТ-75), Ваил Кәбиров (Т-4) үз эшләрен бик яхшы беләләр. Алар биредә чәчүдә беренче тапкыр гына түгел, дистә еллар эшләүчеләр.

x x x

**«Татарстан» колхозы.** Язгы кыр эшләренә хәзерлекне тикшерү барышында хуҗалык механизаторларының кышкы киеренке хезмәте уңай бәя алды. Язгы кыр эшләренә катнашасы тракторлар, тагылма инвентарь сафка бастырылып куелган инде, кырга чыгарга күрсәтмә генә көтәләр.



## Уңган механизатор

Фәрит Гәрәевич Гыйлемшин җиргә береккән механизатор. Зур гаиләнең төпчек баласы булу да ата-ана җире үзенә тарткандыр, бәлки.

Хәер, ничек кенә булмасын Фәрит колхозның иң алдынгы, карусыз, эш сөючән механизаторы булып китте. Совет Армиясе сафларыннан хезмәт срогын тутырып кайткач, ул механик булып эшләде, ә аннан соң үз теләге белән тракторга утырды. Электән дә техниканы биш бармагы кебек белсә дә, ул белемен күтәрү өстендә шөгыльләнергә кирәклеген аңлады һәм хәзер Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумын читтән торып уңышлы тәмамлап килә.

Фәрит Гәрәевичның тракторы кышын-җәен юлда. Район үзәгенә дә, районнан читкә дә чыгып кирәкле йөкләрне ташый ул. Язгы чәчү, урып-җыю чорында ул кырда: чәчә, эшкәртә, ура, суга.

Рәсемдә: «Татарстан» колхозы механизаторы Ф. Гыйлемшин.

Н. Азизов фотосы.

## КАЙДА НӘРСӘ НИЧЕК

Дүрт меңнән артык пакистанлы Хост шәһәре өчен барган сугышларда әфган оппозициясе отрядлары ягыннан торып сугышты.

x x x

7 апрельдә Бөекбританиянең өч транспорт самолеты Төркиягә Гыйрактан качкан көрдләр өчен ярдәм йөге белән килде. 30 тоннага якын азык-төлек, одеал, палатка парашютлар ярдәмендә Британиянең «Геркулес»лары тарафыннан Гыйракның төньяк территорияләренә ташланачак.

x x x

АКШ конгрессында иң бай сенаторлардан саналучы Джон Хайнц авиакатастрофада һәлак булды. Аның самолеты Филадельфия шәһәре өстендә вертолет белән бәрелеште һәм мәктәптән берничә метрда гына җиргә килеп төште. Нәтиҗәдә җиде кеше, шул исәптән ике бала һәлак булды.

x x x

Кыргызстан белән Украина дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешү төзеде. Бу сәяси документ БМОда теркәләчәк. Моның Кыргызстан өчен мөһим әһәмияте бар. Украина ССР Югары Советы Рәисе Л. Кравчук шундый белдерү ясады: Кыргызстан тулысынча Украинага исәп тота ала. Украина Кыргызстан мәнфәгатьләрен БМОда гәүдәләндерәчәк.

x x x

Казахстан президенты Н. Назарбаев республикада кайбер киң куллану товарларын сатудан һәм аерым хезмәт күрсәтүләргә налогны юкка чыгарды. Шул исәптән, 5 процентлы налог ит һәм ит ризыклары, сөт һәм сөт ризыклары, икмәк һәм икмәк ризыклары, он, йомырка, чәй, шикәр тоздан һәм кайбер балалар ризыклары сатудан алынмаячак.

## Сабанда сайрашыр чак җитә

Үткән елгы һава шартларының җайсыз килүе быелгы язгы кыр эшләренә шактый зур кыенлыклар тудырачак. Озак еллар буе эшләгән механизаторлар да мондый елны хәтерләмиләр. Шуңа да карамастан, күп еллар буе тупланган эш тәҗрибәсеннән һәм беркетелгән техникадан рациональ файдаланган очракта, язгы кыр эшләрен вакытында һәм уңышлы башкарып чыгарга мөмкинлек бар дип исәплиләр мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә. Март ахырында һәм 10 апрельдә Кормыш авыл Советы карамагына кергән хуҗалыкларда узган үзара тикшерү дә нәкъ шундый нәтиҗәгә китерде.

Техниканы язгы чәчүгә көйләүгә һәр механизатор җитди карады. Бригадирның техника буенча ярдәмчесе Фәрит Мифтахов җитәкчелегендәге ремонт звеносы эшен аеруча билгеләргә кирәк. Анда тәҗрибәле механизаторлар Юныс Мөхәммәдиев, Шәмсетдин Мусин һәм башкалар кергән иде. Шуңа да техника кабул итү вакытында аның нигездә кырга чыгарга әзер булуы билгеләнде.

Тырмалар, культиваторлар, бөртекле һәм техник культура чәчкечләре — һәммәсе технологик таләпләргә җавап бирерлек итеп әзерләнгән диеп табылды. Шуның өстенә, техниканың ышанычлы кадрлар белән комплектлангал булуын да истән чыгармаска кирәк.

Ә механизаторлар гомумән тәҗрибәле, тапшырылган эшне җиренә җиткереп башкаручан биредә. Елның—елында сынатмаган Ислам Сабиров агрегаты бөртекле культуралар чәчүдә катнашачак. 30 елдан артык язны чәчүдә каршылаган Шамил Яруллин һәм Зәйдулла Мөхәммәтов агрегатлары культивацияләү, дым каплату һәм техник культуралар чәчүдә эшләячәкләр. Аларның һәммәсендә фидакарь хезмәткә зур омтылыш, теләк сизелә.

Яшь механизатор Рәфис Бикбаев та быел бишенче язын чәчүдә каршылый. Аның агрегаты күпьеллык үләннәрне чәчү белән бергә уҗым культураларын тукландыруда катнашачак. Чәчү вакытында ашыгыч ярдәм кирәк була калса техник хезмәт күрсәтү звеносы да даими эшләп торачак. Хуҗалыкара берләшмә чәчүне әнә шундый хәзерлектә каршылый. Аны кыска срокта, яхшы сыйфат белән үткәрүне максат итәләр игенчеләр.

**Ф. МӨХӘММӘТОВА.**
Югары Норлат авылы.

